**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясепоселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**05.05.2023** **№ 565**

**Муниципаль биремне формалаштыру һәм раслау функцияләрен һәм вәкаләтләрен тапшыру турында**

Биектау муниципаль районы бюджеты акчалары чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру, муниципаль хезмәтләр күрсәтү (эшләр башкару) составына, сыйфатына, шартларына, тәртибенә һәм нәтиҗәләренә карата таләпләрне үтәү максатларында, «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләрнең хокукый хәлен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 08 маендагы 83-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру кысаларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен муниципаль биремне формалаштыру һәм раслау һәм аны финанс белән тәэмин итү өлешендә түбәндәгеләргә тапшырырга:

мәгариф учреждениеләре буенча - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә,

мәдәният учреждениеләре буенча - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә,

спорт учреждениеләре буенча – «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин